СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

23.03.2021 Әгерҗе ш. № 7-4

«Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 27.11.2017 № 18-3 номерлы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 27.11.2017 № 18-3 номерлы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарына, 2 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«-инновацион һәм инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен төзелгән сәнәгать паркы, сәнәгать мәйданчыгы белән эш итүче җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Әгерҗе муниципаль районы Советы яисә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарлары нигезендә 0,9 % булды;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru), Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының финанс-бюджет мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Ә.Р.Вәлиев